**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«02» апрель, 2026 ел

№ 211-п

2026 елның 2 кварталына Питрәч муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «2026-2027 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2026-2027 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләре берлеге»коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан торак урыннарның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшерену нәтиҗәләренә ярашлы рәвештә «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлегенең коммерцияле булмаган партнерлыгы» Бәяләр диапазонын билгеләү турында»2026 елның 16 февралендәге 57 номерлы хаты), Питрәч муниципаль районы буенча торак урынының гомуми мәйданының 1 квадрат метры хакының яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзү өчен социаль түләү күләмен исәпләү өчен 2026 елның 2 кварталына 107 070, 00 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Р.Р. Хәсбиев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1633605397